ГЛАВА
ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ
АВЫЛ СОВЕТЫ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

с. Подлесная Шентала

**30.10.2019** **№ 7**

**Алексеевск  муниципаль районының
“Урман Асты Шонталасы җирлеге территориясендәге
Урман Асты Шонталасы авылында
үзара салым кертү һәм гражданнарның үзара салым акчаларыннан
файдалану   мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында “**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ” Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында “Федераль законның 25.1, 56 статьясы,  «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы»  , Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы җирлеге территориясендәге Урман Асты Шонталасы авылында үзара салым кертү  мәсьәләсе буенча   2019 елның 13 нче ноябре көнне 14сәг. 00 минутта гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Алексеевск муниципаль районы  Урман Асты Шонталасы җирлеге территориясендәге Урман Асты Шонталасы авылында  20 20 елда   500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә,үзара салымны ,барлык шул җирлек территориясендә теркәлгән,балигъ булган затлардан, хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар ,1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку бүлеге студентларыннан тыш, җыюга  һәм акчаларны җирле түбәндәге мәсәләләрне хәл итүгә тотуга сез ризамы?

-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;

- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру;
- су насосы сатып алу;
- МТЗ -82.1 тракторына ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- ДПО гаражын ремонтлау;
- халыкның ял итү урыннарын төзекләндерү;
- җирләү урыннарын төзекләндерү.

" ӘЙЕ - КАРШЫ"

3.Халык җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4.Җыенның үткәрү урыны дип авыл мәдәният йортын билгеләргә. Адресы: Татарстан Республикасы.Алексеевск районы,Урман Асты Шонталасы авылы.Габдулла Тукай урамы, 42 йорт.

5.Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы**
**Совет Рәисе** **А.Ә.Җиһаншин**